

Президент В. В.Путин, россиялеләрнен гомер озынлыгы милли проектлар унышынын топ индикаторы булып тора, дип белдерде. Хастаханәләрне оптимальләштергәндә, авыл халкына медицина ярдәмен алу мом-кинлегендә авыл ФАПларына аерым роль бирелә. Шулай, vткән елда Ельник районында модульле оч ФАП тозелгән  – Софьино, Стародевичье белән Старотештелимские Выселки авылларында.
Оч медицина пункты да пациентларны кабул итәргә әзер. Алар кирәкле заманча медицина жиһазлары белән жиһазландырылган. Әмма берәvгә дә сер тvгел, сыйфатлы медицина ярдәме кvрсәткәндә кеше факторы аеруча моһим роль уйный, медик vз вазифаларына ни дәрәжәдә дорес һәм профессиональ караганлыгыннан да тора. Шундыйларнын берсе - Софьино ФАПында фельдшер булып хезмәт итә торган Ильмира Рәшид кызы Мещерова.      Софьино авылында яна ФАП ачылгач, мона караган Новоникольское авыл жир леге юлларнын тозеклеге белән аерылып торуы бик тә моһим, чонки монда теләсә кайсы транспорт торендә дә йорергә була. Авыл халкы монын очен район башлыгы Л.В.Самылинага рәхмәтле. Любовь Викторовна экскаватор хужасы белән vз вакытында килешv тозегән. Медпунктка шактый кочле кар явып киткәннән сон проблемасыз килергә була. Быелгы каты бураннарда трактор эшләгән.
ФАП турында сvзебез, шуна кайтыйк. Пациентларнын берсе булган пенсионер Н.И.Замотаева ФАП турында болай ди: «Авылыбыздагы яна ФАПтан мин бик канәгать, - ди Нина Ивановна. – Мин стажлы гипертоник. Мина бу пункт - чын коткару. Уколга йорим. Ботен хезмәт юлым колхоз фермасында узды. Сәламәтлегемне дә шунда югалттым. Ә хәзер колхоз да, ферма да юк, пенсия дә бик аз - минималка. Мондый пенсиягә такси чакыртып район vзәгенә йори алмас та идек; саулык белән зур проблемалар чыккач кына барабыз. Ә хәзер медицина ярдәме монда, ойгә килде дип әйтергә була. Һәм ин моһиме, безгә нинди шәп фельдшерны билгеләделәр! Игътибарлы, аралашучан, профессиональлелек сизелә, чын табиб шундый булырга тиеш тә.»
Быелнын 18 февралендә һәрвакыт ачык йоз белән каршы алган яшь хатын - фельд шер Ильмира Рәшид кызы Мещерова билгеләнгән. Биредә аз эшләгән булуына карамастан, vзен судагы балык кебек тота һәм кешеләр ышанычын да яулап олгергән. Бу ФАП жиһазландырылган һәм заманча жиһазлар белән ул белеп эшли. Әйтеп китәргә кирәк, И.Р.Мещерованын торле медицина медучреждениеләрдә эшләv тәжрибәсе зур. Ул - нәселдән килгән табиб. Фельдшерыбызнын әнисе дә, пенсиягә кадәр, 30 ел фельдшер булып эшләгән. Зәйнәб Абидулла кызын барлык пациентлар да ярата лар һәм хормәт итәләр. Темник районынын фельдшер-акушерлык пункты булган Итяково авылына ул, кешеләрне дәвалау һәм коткару очен, жәяv йорегән. Ә vзе, гаиләсе белән, Тювеево

авылында яши, анда 1985 елда Ильмира исемле кызы туа. Әнисе һонәренә булган мәхәббәтне кыз ана соте белән сендергән. Авыру газапларын жинеләйтvдән, аларга сәламәтлек шатлыгын кайтарудан да зур бәхет бармы?!
Ильмира Рәшид кызы Мещерова туган авылы мәктәпбеннән сон турыдан-туры Темников шәһәрендәге медицина училищесына укырга керә. Аны тәмамлап, туганнары чакыруы буенча, Башкортстанга китә. Уфа шәһәрендәге балалар поликлиникасындагы прививка кабинетында эшли, аннары участок врачы белән кабул итvдә дә хезмәт итә. Yз кочен Петербургта сынап карарга булган язма героебыз. Башта ана шәһәрнен наркодиспансерында эш тәкъдим итәләр, аннары гинекология бvлегендә эшли. 2012 елда ныклы белем багажы гына тvгел, бай тәжрибә туплап, туган Темник районына әйләнеп кайта. Явас дәваханәсендәге бала тудыру бvлегендә акушерка булып эшли. Профессиональ дәрәжәдә башкарган капельниклар, уколлар яшь хатын-кыз тормышынын зур олешен тәшкил итә. Тагын бер ел эшләгәч, язмышын очрата. Ул Рушан Шамиль улы Мещеровка киявгә чыга. Ельник районы жирлегенә бәхет елмая, чонки Рушан Шамиль улы бу районнын Кvгеш-Акчеево авылда туып-vскән. Хәзерге вакытта Ильмира Рәшид кызы, каенанасы Арифә Гани кызы һәм ике баласы белән, Ельникнын Сельхозтеника поселогында ике бvлмәле фатирда яши. Кызы Каринага 10 яшь, ул Акчеево мәктәбенен 4 сыйныф укучысы. Улы Ильнурга 5 яшь; әнисе эштә булганда, әбисе тәрбиясендә.
Ильмира Рәшид кызы очраткан топ кыенлык - эшенен ойдән ераклыгы. Хезмәтенә барып житv очен, ул дистәләрчә чакрым юл vтәргә тиеш. Кайчагында эшкә ире алып бара, кайчагында такси ялларга туры килә; транспорт чыгымы - хезмәт хакыннан аена минус ун мен сум. Һонәргә тугрылык һәм ана мәхәббәт кына юата аны. Тәжрибәле табибны Софьинода фельдшер итеп бил гелөгәнче, ул берничә ай Ельниктагы дәваханәдә «кызыл зона»да мәкерле авырулар белән эшләгән.
И.Р.Мещерова ФАПында пациентларнын нинди хезмәтләр ала алуы, нәрсә эшләгәне турында озын-озак сойли ала, әмма берничә мәгълуматны сезгә дә ишеттерәсебез килә. Бу медицина учагында жиһазлар заманча; беренче ярдәм кvрсәтv һәм авыруларны озак дәвалау очен кирәкле ботен нәрсә дә бар. Пункт хәтта ЭКГ аппараты белән дә жиһазландырылган, йорәк эшчәнлеген тикшерv очен якын арада интернетны тоташтырырлар дип ометләнә табиб. Йорәк очен дефибриллятор да, жиһазларны һәм инвентарьны стерильләштерv аппаратлары да бар. ФАПта сейф һәм суыткыч белән жиһазландырылган препаратларны саклау кабинеты аерым урнашкан. ИВЛ аппараты, ингалятор, спиртотест, глюкометр, кvз тобен карау очен прибор да бу пунктта. Әлбәттә, бәдрәф, раковина бар. Ягулык урыны - кочегарка очен дә шулай ук Ильмира Рәшид кызы жаваплы.
Софьино авылында барлыгы 78 кеше яши икән. Биредә кечкенә балалар һәм яшvсмерләр юк. Нигездә, даими медицина ярдәменә мохтаж пенсионерлар гына тора. Бу ФАПта кvрше Муравлянка һәм Новоникольск пациентларын да кабул итәргә әзер фельдшер булып хезмәт итvче Ильмира Рәшид кызы Мещерова. Бер сvз белән әйткәндә, биредә «Саләмәтлек саклау-Здравоохранение» милли проекты халыкка хезмәт итә.

**Наилә НАСЫРОВА**